**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлегенең Буралы-Чишмә авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**22 ноябрь 2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 22 ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыенының «2024 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге Буралы-Чишмә авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; вакытлы хәрби хезмәт узучы, махсус хәрби оперциядә катнашучылардан , көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1) Буралы-Чишмә авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

2) «Беларус-82,1» тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);

3) коены төзү һәм ремонтлау , колонкалар һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү.;

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 45 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 37 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 37 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлегенең Буралы-Чишмә авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2024 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге Буралы-Чишмә авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; вакытлы хәрби хезмәт узучы, махсус хәрби оперциядә катнашучылардан , көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1) Буралы-Чишмә авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

2) «Беларус-82,1» тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);

3) коены төзү һәм ремонтлау , колонкалар һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү.;

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яңа Имән авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Гараев Р. Ф. Гараев